ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 137-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.А. Чубаров тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 137-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 521-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.А. Чубаров тарафыннан
кертелә

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 3 өлешенең 2 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш); 2025, № 49 (I өлеш), № 75 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле «ж» пунктчасы өстәп, үзгәреш кертергә:

ж) «хезмәт шартнамәсен төзүдән эш бирүченең Россия Федерациясе Хезмәт кодексында билгеләнгән гарантияләрне бозарлык итеп баш тартуы, эш урынына кире кайтарылу, хезмәт хакын түләттерү, шул исәптән ихтыярсыздан эшкә чыкмаган вакыт өчен, эш бирүченең хокукка каршы гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында китерелгән мораль зыянны компенсацияләү;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын федераль законнарга туры китерүгә юнәлдерелгән.

«Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Федераль законның 20 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 4 ноябрендәге 407-ФЗ номерлы Федераль закон белән дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучы дәүләт юридик бюросы һәм адвокатлар, әгәр дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия булган гражданнар судларда хезмәт шартнамәсен төзүдән эш бирүченең Россия Федерациясе Хезмәт кодексында билгеләнгән гарантияләрне бозарлык итеп баш тартуы, эш урынына кире кайтарылу, хезмәт хакын түләттерү, шул исәптән ихтыярсыздан эшкә чыкмаган вакыт өчен, эш бирүченең хокукка каршы гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында китерелгән мораль зыянны компенсацияләү турындагы эшләр каралганда дәгъвачылар (гариза бирүчеләр) булсалар, судларда, дәүләт органнарында һәм муниципаль органнарда, оешмаларда мондый гражданнарның мәнфәгатьләрен чагылдыралар дип билгеләнә.

Бәян ителгәнгә бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының «Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия гражданнарның категорияләре һәм мондый ярдәмне күрсәтү очраклары» 12 статьясына тиешле үзгәрешләр кертелергә тиеш.

Закон проекты ике статьядан тора.

Закон проектының 1 статьясында 12 статьяга үзгәреш кертү күздә тотыла.

2 статьяда Татарстан Республикасы законының үз көченә керү тәртибе билгеләнә: ул рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керәчәк.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының үз көчен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башка Татарстан Республикасы законнарын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында «Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар бүлеп бирүне таләп итми.